**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте авылында

**28 октябрь 2022 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Шешминка крепосте авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән, күпбалалы аналардан, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан тыш

2. Алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Шешминка крепосте авылында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Зиратланы төзекләндерү, реконструкцияләү, карап тоту (капкалар һәм киртәләрне кую (ремонтлау), чүп савытларын урнаштыру, агачларны кисү, корысарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, хуҗалык инвентаре саклау өчен хуҗалык блогы төзү, керү юлларын, юлларны төзекләндерү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документациясе өчен түләү) Шешминка Крепосте авылында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу;
- Җәйге һәм кышкы чорда юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлауга, урамнарны кышкы чорда кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары сатып алуга, тракторчыга хезмәт хакын түләүгә) Шешминка Крепосте авылында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен чыгымнар

- Шешминка Крепосте авылында су күтәрү манарасы өчен тирәнлек насосы сатып алу;

- Андреевка ФАПында пандуслар урнаштыру.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Сидоров